ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

17.09.2018 г. Казань № 125-од

"Минем нәселем"
республика балалар-яшүсмерләр
генеалогик тикшеренүләр
конкурсы турында

Нәсел гореф-гадәтләрен саклап калу һәм үстерү, туганнар арасындагы элемтәләрне һәм варислыкны ныгыту, Татарстанның һәм үз гаиләңнең тарихы белән кызыксынуны арттыру, үсеп килүче буында тарихи аң булдыру һәм аларда ватанпәрвәрлек хисен тәрбияләү, шулай ук архив материаллары белән эшләргә өйрәтү, тарихи һәм туган як әдәбиятын укуга җәлеп итү максатларында БОЕРЫК БИРӘМ:

1. "Минем нәселем" республика балалар-яшүсмерләр генеалогик тикшеренүләр конкурсын оештырырга һәм 2018 елның 1 октябреннән алып 25 октябренә кадәр үткәрергә.
2. Кушымта итеп бирелгән 2018 елда "Минем нәселем" республика балалар-яшүсмерләр генеалогик тикшеренүләр конкурсы турында нигезләмәне расларга.
3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис Г.З. Габдрахманова

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 2018 елның 17 сентябрендәге 125-од номерлы боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

2018 елда
"Минем нәселем" республика балалар-яшүсмерләр генеалогик тикшеренүләр конкурсы турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге 2018 елда "Минем нәселем" республика балалар-яшүсмерләр генеалогик тикшеренүләр конкурсы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә, конкурс) конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибен, конкурс эшләрен бәяләү критерийларын билгели.

1.2. Конкурсны оештыручы – Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты (алга таба – ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты).

1.3. Конкурс 2018 елның 1 октябреннән алып 25 октябренә кадәр үткәрелә.

1.4. Конкурсны үткәрү тәртибе, сроклары, шартлары һәм катнашу өчен сайлап алу критерийлары турында мәгълүмат ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының "Минем нәселем" республика балалар-яшүсмерләр генеалогик тикшеренүләр конкурсы турында" боерыгы үз көченә кергән көннән алып 3 эш көне эчендә "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ТР Архив дәүләт комитетының рәсми сайтына (http://arhiv.tatarstan.ru) (алга таба – ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәсми сайты) урнаштырыла.

## II. Конкурсның максаты һәм бурычлары

2.1. Конкурсның төп максаты балаларның һәм яшүсмерләрнең үз гаиләләренең кыйммәтләре белән кызыксынуларын арттырудан, нәсел-гаиләләрнең гореф-гадәтләрен торгызудан гыйбарәт.

2.2. Конкурсның бурычлары:

гаилә тарихының ил һәм туган як тарихына ни дәрәҗәдә үрелүен өйрәнү аша балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирүгә ярдәм итү;

гаиләдәге гореф-гадәтләрне һәм буыннар арасында элемтәләрне ныгытуга ярдәм итү;

нәселләр тарихы буенча тикшеренүләр традицияләрен саклап калу һәм үстерү;

архив материаллары белән эшләргә өйрәтү, тарихи һәм туган як әдәбиятын укуга җәлеп итү.

## III. Конкурсның катнашучылары

3.1. Конкурста гомуми белем бирү оешмаларында белем алучылар дүрт яшь төркеме буенча катнашырга хокуклы

1 нче төркем –1-4 сыйныф укучылары;

2 нче төркем –5-8 сыйныф укучылары;

3 нче төркем – 9-11 сыйныф укучылары;

4 нче төркем – һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучы 18 яшькәчә укучылар.

Конкурсның җиңүчеләре һәр яшь төркеме буенча аерым билгеләнә.

3.2. 16 яшьтән кечерәк булган катнашучының конкурста катнашуга гаризасы катнашучы ата-анасының берсе (яки законлы вәкиле) тарафыннан имзалана.

3.3. Конкурска, 1 нче яшь төркеменә караган катнашучылардан тыш, бары тик үзләре тарафыннан башкарылган эшләр генә кабул ителә.

## IV. Конкурстагы жюри

4.1. Конкурстагы жюри (алга таба – жюри) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкилләреннән, архив эше өлкәсендәге белгечләрдән, мөгаллимнәрдән, фәнни бергәлек вәкилләреннән жюри рәисе, рәис урынбасары һәм әгъзалары составында кимендә 9 (тугыз) кешедән төзелә.

4.2. Жюри составы ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

4.3. Конкурска тапшырылган эшләрне бәяләгәндә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

тапшырылган материалларны бәяләү критерийлары нигезендә бәяләүнең объективлылыгы;

конфиденциальлек.

4.4. Конкурс эшләрен бәяләүне бәяләү критерийлары нигезендә эксперт бәяләве алымы белән жюри әгъзалары башкара.

4.5. Жюри әгъзасы һәр критерий буенча балл куя, һәм алар кушыла. Һәр критерий буенча балл саны 10-баллы шкала буенча (0 алып 10 кадәр) билгеләнә.

Баллар "Индивидуаль бәяләү бите"нә язып куела, жюри әгъзасы имзасы белән таныклана һәм жюри рәисенә тапшырыла (3 нче кушымта).

4.6. Әлеге Нигезләмәнең 7 бүлегендә күрсәтелгән критерийлар буенча жюри әгъзалары тарафыннан куелган балларны кушканнан соң чыккан нәтиҗәләр буенча катнашучыларның йомгак рейтингы төзелә, ул жюри рәисе һәм әгъзалары тарафыннан имзалана.

Жюри утырышы жюри әгъзаларының гомуми саныннан 2/3 өлеше катнашкан очракта хокукка ия дип санала.

4.7. Жюри карары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, жюри рәисе яки аны алмаштыручы зат һәм жюри әгъзалары тарафыннан имзалана.

4.8. Жюри карарлары утырышта булган әгъзалары саныннан тавышларның гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта жюри рәисе тавышы хәлиткеч була.

## V. Конкурсны үткәрү шартлары һәм тәртибе

5.1 Конкурста катнашу өчен документлар пакеты 2018 елның 1 октябреннән алып 25 октябренә кадәр электрон рәвештә konkurs.genealogia@yandex.ru электрон почта адресына юллана һәм/яки кулдан тапшырыла, Казан ш., 8 Март ур., 5а й. адресы буенча "Татарстан Республикасы Дәүләт архивы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенә "Конкурс" тамгасы белән җибәрелә, ул түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1 нче кушымта күрсәтелгән форма буенча гариза;

персональ белешмәләрне эшкәртүгә рөхсәт (2 нче кушымта).

конкурс материаллары комплекты.

5.2 Конкурс материаллары яшь төркемнәренә ярашлы рәвештә түбәндәге форматларда тапшырыла):

1 нче төркем – иҗади эш (гаилә агачы рәсеме, аңлатмалар бирелгән фотоальбом, коллажлар, схемалар, плакатлар, аппликация, табигый материал кулланып һәм тукымадан эшләнгән күләмле эш һ.б.). Бер катнашучы тапшырган эшләрнең саны чикләнми;

2 нче төркем - иҗади эш (гаилә агачы рәсеме, аңлатмалар бирелгән фотоальбом, коллажлар, схемалар, плакатлар, аппликация, табигый материал кулланып һәм тукымадан эшләнгән күләмле эш һ.б.) һәм 14 зурлыгындагы Times New Roman шрифты белән язылып, сулдан 2 см, уңнан 1,5 см, өстән һәм астан 2 см буш ара калдырып эшләнгән А4 форматлы 10 биткә кадәр күләмдә язма эш (реферат, эссе, инша һ.б.). Кушымталарның күләме чикләнми;

3 нче төркем – теләсә нинди форматта бирелгән тикшерү эше (язма эш (аналитик хисап, күләме 14 зурлыгындагы Times New Roman шрифты белән язылып, сулдан 2 см, уңнан 1,5 см, өстән һәм астан 2 см буш ара калдырып эшләнгән А4 форматлы 15 биткә кадәр), видеоэшләр (гаилә тарихы турында өйдә төшерелгән фильмнар (дәвамлылыгы 10 минутка кадәр), Microsoft Power Point форматында презентацияләр (50 слайдка кадәр);

4 нче төркем – архив документларына нигезләнгән проект-тикшеренү эше (фәнни хисап, фәнни мәкалә, доклад). Төп тасвирлама күләме - 14 зурлыгындагы Times New Roman шрифты белән язылып, сулдан 2 см, уңнан 1,5 см, өстән һәм астан 2 см буш ара калдырып эшләнгән А4 форматлы 20 биткә кадәр.

5.3 Конкурска җибәрелгән материалларга рецензияләр язылмый, һәм алар кире кайтарылмый.

5.4 Конкурска материаллар тапшыру авторның аларны конкурсның оештыручысы чараларында, авторлык хокукларын саклап, файдаланылуына рөхсәт бирүне аңлата.

5.5 Җибәрелгән материаллар авторның (авторларның) ризалыгы белән Татарстан Республикасының Бердәм архив мәгълүмат системасына кертелү өчен файдаланылырга мөмкин.

5.6 Документларны кабул итүнең әлеге Нигезләмәнең 5.1 пунктында күрсәтелгән срогы тәгәлләнгәннән соң җибәрелгән материаллар каралмый.

## VI. Конкурс эшләренең эчтәлегенә һәм бизәлешенә карата таләпләр

6.1. 1 – 4 яшь төркемнәре катнашучыларының конкурс эшләре эчтәлегенә карата таләпләр:

эшнең максатлары һәм бурычлары булу;

үз нәселенең тарихы турында нигезләнгән һәм документлар белән расланган мәгълүматның булуы, материалны әзерләгәндә архив документларының файдаланылуы;

ата-бабаларның тормышы, аларның ил, туган як тарихында тоткан урыны турында белешмәләр булу (мондый мәгълүмат булган очракта);

гаиләсенең милли тамырлары һәм ата-бабаларының кайсы конфессиягә каравы турында белешмәләр булу (мондый мәгълүмат булган очракта).

Эштә гаилә тарихыннан документлар белән раслана алмаган кызыклы фактлар күрсәтелергә мөмкин.

6.2. Эшләр рус һәм (яки) татар телләрендә тапшырыла.

## VII. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

7.1. 1 нче төркем эшләрен бәяләү критерийлары:

конкурсның максатларына һәм бурычларына туры килү (0 баллдан алып 10 баллга кадәр);

эшнең бизәлешендә оригинальлек һәм аңа иҗади якын килү (0 баллдан алып 10 баллга кадәр);

идеяне техник яктан гамәлгә ашыру дәрәҗәсе (0 баллдан алып 10 баллга кадәр);

конкурс эшен әзерләгәндә мөстәкыйльлек дәрәҗәсе (0 баллдан алып 10 баллга кадәр);

китерелгән тарихи фактларның дөреслеккә туры килүе (0 баллдан алып 10 баллга кадәр).

7.2. 2 нче – 3 нче төркем эшләрен бәяләү критерийлары:

конкурсның максатларына һәм бурычларына туры килү (0 баллдан алып 10 баллга кадәр);

китерелгән тарихи фактларның дөреслеккә туры килүе, архив чыганакларыннан файдалану дәрәҗәсе (0 баллдан алып 10 баллга кадәр);

гаилә кыйммәтләрен һәм традицияләрен ачу дәрәҗәсе (0 баллдан алып 10 баллга кадәр);

үз нәселеңнең тарихын өйрәнү тирәнлеге (0 баллдан алып 10 баллга кадәр);

үз фамилияңнең барлыкка килүе турында, ата-бабаларның милли тамырлары, кайсы конфессиягә караулары хакында белешмәләр булу һәм аларның нигезләнгән булуы (0 баллдан алып 10 баллга кадәр);

нәсел вәкилләренең ил һәм туган як тарихында һәм тормышында тоткан урыны турында белемнәрнең тирәнлеге (0 баллдан алып 10 баллга кадәр);

эшнең сәнгати яктан уңышлы яклары (әдәби тел, образлы бәян итү, күрсәтмә материалларның бизәлеш-ясалыш сыйфаты) (0 баллдан алып 10 баллга кадәр);

файдаланылган тарихи чыганакларның күптөрлелеге (документлар, хатлар, бүләкләр, гаилә риваятьләре һ.б.) (0 баллдан алып 10 баллга кадәр).

7.3 4 нче төркем эшләрен бәяләү критерийлары:

тикшеренү проблемасының тулылыгы, моңа үз фамилияңнең барлыкка килүе турында, ата-бабаларның милли тамырлары, кайсы конфессиягә караулары, аларның тормышы хакында нигезләнгән белешмәләр дә керә (0 баллдан алып 10 баллга кадәр);

тарихи белешмәләргә анализның тирәнлеге, абруйлы чыганакларга сылтамаларның һәм үзе чыгарган нәтиҗәләрнең булуы (0 баллдан алып 10 баллга кадәр);

файдалану рөхсәт ителгән барлык төп архив чыганакларына мөрәҗәгать итү, файдаланылган әдәбиятның күләме зур булу (0 баллдан алып 10 баллга кадәр);

структураның төгәллеге һәм бәян ителгән материалның эзлеклелеге (0 баллдан алып 10 баллга кадәр);

эшнең гамәли һәм фәнни кыйммәте (0 баллдан алып 10 баллга кадәр).

## VIII. Җиңүчеләрне билгеләү тәртибе, нәтиҗәләр чыгару һәм җиңүчеләрне бүләкләү

8.1. Документлар пакетын тапшыру төгәлләнгәннән соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча жюри утырышы үткәрелә.

8.2. Конкурсның җиңүчеләре исемлеге катнашучыларның һәр яшь төркеме буенча йомгак рейтингына нигезләнеп төзелә.

8.3. Рейтингта конкурс йомгаклары буенча үз яшь төркемнәрендә беренче өч урынны алган катнашучылар конкурсның җиңүчеләре дип танылa.

8.4. Конкурсның җиңүчеләре исемлеге, жюриның йомгак утырышы беркетмәсенә нигезләнеп, беркетмә имзаланган көннән алып 3 (өч) эш көненнән дә соңга калмыйча ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән раслана.

8.5. Конкурсның җиңүчеләре исемлеге боерык имзаланган вакыттан алып 3 эш көне эчендә ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайтына куела.

8.6. Конкурсны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 13 сентябрендәге 2422-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә гамәлгә ашырыла.

8.7. Конкурсның җиңүчеләре конкурс дипломнары һәм түбәндәге истәлекле бүләкләр белән бүләкләнә: планшет – I урын өчен, кәрәзле телефон – II урын өчен, электрон китеп – III урын өчен.

## IX. Өстәмә мәгълүмат

9.1. Тапшырылган эшләргә авторлык хокукы конкурс катнашучыларыныкы булып кала.

9.2. Конкурсны оештыручы конкурс эшләрен, шул исәптән конкурс гаризаларына беркетеп җибәрелгән фотографияләрне, видеороликларны һәм башка

документларны, авторлык хокукларын саклап калып, архив чараларын таныту максатларында, мәгълүмат бирү һәм презентация материалларын төзү өчен куллану хокукына ия.

9.3. Җиңүчеләр исемлегенә кермәгән барлык конкурс катнашучылары конкурста катнашучылар сертификатларын электрон рәвештә ала, алар катнашучының e-mail почта адресына җиңүчеләр исемлеге куелганнан соң 10 эш көне эчендә җибәрелә.

2018 елда “Минем нәселем” республика балалар-яшүсмерләр генеалогик тикшеренүләр конкурсы турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

“Минем нәселем”
республика балалар-яшүсмерләр генеалогик тикшеренүләр конкурсында катнашуга
гариза

| | |
|---|---|
| 1. Фамилия, исем, атасының исеме: | |
| 2. Катнашучының яше | |
| 3. Катнашучы белем ала торган мәгариф оешмасы: | |
| 4. Катнашучы йортының индексы күрсәтелгән тулы адресы: | |
| 5. Катнашучының элемтә телефоннары: | |
| 5. Катнашучының E-mail адресы: | |
| 7. Конкурс эшенең исеме: | |
| 8. Эш тәкъдим ителгән яшь төркеме | |

2018 елда “Минем нәселем” республика балалар-яшүсмерләр генеалогик тикшеренүләр конкурсы турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга
рөхсәт

2018 елда “Минем нәселем” республика балалар-яшүсмерләр генеалогик тикшеренүләр конкурсының оештыручысына, “Персональ мәгълүматлар турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, түбәндәге күләмдә минем персональ мәгълүматларымны эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга (аларны миннән һәм/яки теләсә кайсы өченче заттан алуны да кертеп) рөхсәт бирәм:

Эшкәртелә торган персональ мәгълүматлар исемлеге (Ф.И. Аи (соңгысы – булган очракта), җенес, туу датасы һәм урыны, гражданлык, шәхесне таныклый торган документның реквизитлары (документның төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон номеры), электрон почта адресы)

______________________________________________________________

(Ф.И.Аи. (соңгысы – булган очракта), имза)

______________________

(дата)

2018 елда “Минем нәселем” республика балалар-яшүсмерләр генеалогик тикшеренүләр конкурсы турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

1 нче төркем эшләрен индивидуаль бәяләү битләре:

| Критерийлар | (0 баллдан алып 10 баллга кадәр) |
|---|---|
| конкурсның максатларына һәм бурычларына туры килү | |
| эшнең бизәлешендә оригинальлек һәм аңа иҗади якын килү | |
| идеяне техник яктан гамәлгә ашыру дәрәҗәсе | |
| конкурс эшен әзерләгәндә мөстәкыйльлек дәрәҗәсе | |
| китерелгән тарихи фактларның дөреслеккә туры килүе | |

2 нче – 3 нче төркем эшләрен индивидуаль бәяләү битләре:

| Критерийлар | (0 баллдан алып 10 баллга кадәр); |
|---|---|
| конкурсның максатларына һәм бурычларына туры килү | |
| китерелгән тарихи фактларның дөреслеккә туры килүе, архив чыганакларыннан файдалану дәрәҗәсе | |
| гаилә кыйммәтләрен һәм традицияләрен ачу дәрәҗәсе | |
| үз нәселеңнең тарихын өйрәнү тирәнлеге | |
| үз фамилияңнең барлыкка килүе турында, ата-бабаларның милли тамырлары, кайсы конфессиягә караулары хакында белешмәләр булу һәм аларның нигезләнгән булуы | |

| | |
|---|---|
| нәсел вәкилләренең ил һәм туган як тарихында һәм тормышында тоткан урыны турында белемнәрнең тирәнлеге | |
| эшнең сәнгати яктан уңышлы яклары (әдәби тел, образлы бәян итү, күрсәтмә материалларның бизәлеш-ясалыш сыйфаты) | |
| файдаланылган тарихи чыганакларның күптөрлелеге (документлар, хатлар, бүләкләр, гаилә риваятьләре һ.б.) | |

4 нче төркем эшләрен индивидуаль бәяләү битләре:

| Критерийлар | (0 баллдан алып 10 баллга кадәр); |
|---|---|
| тикшеренү проблемасының тулылыгы, моңа үз фамилияңнең барлыкка килүе турында, ата-бабаларның милли тамырлары, кайсы конфессиягә караулары, аларның тормышы хакында нигезләнгән белешмәләр дә керә | |
| тарихи белешмәләргә анализның тирәнлеге, абруйлы чыганакларга сылтамаларның һәм үзе чыгарган нәтиҗәләрнең булуы | |
| файдалану рөхсәт ителгән барлык төп архив чыганакларына мөрәҗәгать итү, файдаланылган әдәбиятның күләме зур булу | |
| структураның төгәллеге һәм бәян ителгән материалның эзлеклелеге | |
| эшнең гамәли һәм фәнни кыйммәте | |